**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 1 август № 529

г. Казань

Татарстан Республикасының тармак стратегияләрен тормышка ашыруны мониторинглауны һәм тикшерүдә тотуны әзерләү, төзәтмәләр кертү, гамәлгә ашыру тәртибе турында

«Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 ел, 28 июнь, ФЗ-172 нче Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру кысаларында Татарстан Республикасында тармак стратегияләрен тормышка ашыруны мониторинглауны һәм тикшерүдә тотуны әзерләүгә, төзәтмәләр кертүгә, гамәлгә ашыруга бердәм якын килүне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының тармак стратегияләрен тормышка ашыруны мониторинглауны һәм тикшерүдә тотуны әзерләү, төзәтмәләр кертү, гамәлгә ашыру тәртибен (карарга теркәлә) расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 1 август, 529 нчы карары белән расланды

**Татарстан Республикасының тармак стратегияләрен тормышка ашыруны мониторинглауны һәм тикшерүдә тотуны әзерләү, төзәтмәләр кертү, гамәлгә ашыру тәртибе**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасының тармак стратегияләрен тормышка ашыруны мониторинглауны һәм тикшерүдә тотуны әзерләү, төзәтмәләр кертү, гамәлгә ашыру тәртибе (алга таба – Тәртип) «Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 ел, 28 июнь, ФЗ-172 нче Федераль закон нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасының тармак стратегияләрен тормышка ашыруны мониторинглауны һәм тикшерүдә тотуны әзерләгәндә, төзәтмәләр керткәндә, гамәлгә ашырганда стратегик планлаштыруда катнашучылар хезмәттәшлегенең төп кагыйдәләрен билгели.

1.2. Тәртиптә түбәндәге төшенчәләр файдаланыла:

1) Татарстан Республикасының тармак стратегияләре (алга таба – тармак стратегияләре) – озак вакытлы чорга Татарстан Республикасы икътисадының билгеле бер тармагын яки социаль-икътисадый үсеш өлкәсен үстерүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы дәрәҗәсендә дәүләт идарәсе өстенлекләрен, максатларын һәм бурычларын билгели торган стратегик планлаштыру документлары;

2) җаваплы үтәүче – тармак стратегияләрен әзерләү, төзәтмәләр кертү, тормышка ашыруны мониторинглау һәм тикшерүдә тоту өчен җаваплы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы;

3) тармак стратегияләрен әзерләү – озак вакытлы чорга Татарстан Республикасы икътисадының билгеле бер тармагын яки социаль-икътисадый үсеш өлкәсен үстерүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы дәрәҗәсендә дәүләт идарәсе өстенлекләрен, максатларын һәм бурычларын билгеләү буенча стратегик планлаштыруда катнашучылар эшчәнлеге;

4) тармак стратегияләренә төзәтмәләр кертү – тармак стратегияләренә үзгәрешләр кертү;

5) тармак стратегияләрен тормышка ашыруны мониторинглау һәм тикшерүдә тоту – Татарстан Республикасын стратегик планлаштыруда катнашучыларның тармак стратегияләрен тормышка ашыру барышын комплекслы бәяләү буенча эшчәнлеге.

Тәртиптә файдаланыла торган башка төшенчәләр «Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 ел, 28 июнь, ФЗ-172 нче Федераль законда кабул ителгән мәгънәләрдә кулланыла.

1.3. Тармак стратегияләре Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен, Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына еллык Юлламасын, Татарстан Республикасы Президентының һәм Татарстан Республикасы Премьер-министрының йөкләмәләрен

кабул итү, аларга төзәтмәләр кертү белән бәйле рәвештә, шулай ук тармак һәм муниципаль стратегияләрне тормышка ашыру нәтиҗәләрен яисә аларның этапларын, республикадагы һәм илдәге гомуми социаль-икътисадый хәл үзгәрешләрен исәпкә алып әзерләнә һәм төзәтмәләр кертелә.

1.4. Тармак стратегияләрен әзерләүдә карамакларында булган өлкә нигезендә мәнфәгатьле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм башка стратегик планлаштыруда катнашучылар (алга таба – әзерләүдә катнашучылар) катнаша.

## 2. Тармак стратегияләре эчтәлегенә таләпләр

2.1. Тармак стратегияләре үз эченә түбәндәгеләрне алырга тиеш:

1) тармак стратегиясе паспорты;

2) Татарстан Республикасы икътисадының тиешле тармагында яки социаль-икътисадый үсеш өлкәсендә максатлар, бурычлар, аларга нәтиҗәле ирешү һәм хәл итү өстенлекләре һәм ысуллары;

3) түбәндәгеләрне үз эченә алган Татарстан Республикасы икътисадының тиешле тармагы яки социаль-икътисадый үсеш өлкәсе торышына бәяләмә:

алдагы чор өчен (кимендә 3 ел) тармак (социаль-икътисадый үсеш өлкәсе) үсешенә ретроспектив анализ;

тармакның (социаль-икътисадый үсеш өлкәсенең) гамәлдәге торышына, аның үсеш потенциалына бәя;

тармакны (өлкәне) үстерүдә булган проблемалар тасвирламасы, аларның барлыкка килү сәбәпләре анализы һәм, проблемалар хәл ителмәгән очракта, хәлнең тискәре үсешенә бәяләмә;

4) озак вакытлы чорга Татарстан Республикасы икътисады тиешле тармагының яки социаль-икътисадый үсеш өлкәсенең үсеш күрсәткечләренең максатчан мәгънәләре;

5) тармак стратегиясен тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары;

6) Татарстан Республикасы икътисадының тиешле тармагын яки социаль-икътисадый үсеш өлкәсен үстерүнең стратегик куркынычлары;

7) тармак стратегиясендә чагылыш тапкан максатларга һәм бурычларга ирешү дәрәҗәсен тасвирлый торган сан күрсәткечләрен үз эченә алган тармак стратегиясен тормышка ашырудан көтелә торган нәтиҗәләр;

8) тармак стратегиясен тормышка ашыру буенча чаралар планы.

## 3. Тармак стратегияләрен әзерләү һәм килештерү тәртибе

3.1. Тармак стратегияләре озак вакытлы чорга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразы эшләнә торган чордан артмаган озак вакытлы чорга, Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен тормышка ашыруны тәэмин итү максатларында эшләнә.

3.2. Тармак стратегияләре Россия Федерациясен стратегик планлаштыру, Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясе, озак вакытлы чорга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразы һәм озак вакытлы чорга Татарстан Республикасы бюджет фаразының тармак документларын исәпкә алып эшләнә.

3.3. Тармак стратегияләре Татарстан Республикасы дәүләт программаларын, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең программа-максатчан документларын һәм башка стратегик планлаштыру документларын әзерләгәндә һәм аларга төзәтмәләр керткәндә исәпкә алына.

3.4. Җаваплы үтәүчеләр тармак стратегияләре проектларын Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына һәм «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә (алга таба – «ИСТҮ» ДБУ) карап тикшерү һәм килештерү өчен җибәрә. Кирәк булган очракта, җаваплы үтәүчеләр аларны эшләп бетерә һәм кабат Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы һәм «ИСТҮ» ДБУ белән килештерә.

3.5. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы һәм «ИСТҮ» ДБУ килештергән тармак стратегияләре проектлары җаваплы үтәүчеләр тарафыннан Татарстан Республикасы Премьер-министрына яки тиешле тармакны җитәкли торган Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарына карап тикшерүгә җибәрелә.

3.6. Татарстан Республикасы Премьер-министры яки тиешле тармакны җитәкли торган Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары тәкъдимнәрен исәпкә алып эшләнеп беткән тармак стратегияләре ведомство боерыклары белән раслана һәм җаваплы үтәүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырыла.

3.7. Тармак стратегияләрен әзерләү һәм төзәтмәләр кертүне яраштыруны һәм методик тәэмин итүне «ИСТҮ» ДБУ белән берлектә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы алып бара.

## 4. Тармак стратегияләрен тормышка ашыруны мониторинглауны һәм тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе

4.1. Тармак стратегияләрен тормышка ашыруны мониторинглау һәм тикшерүдә тоту тармак стратегияләренең максатчан күрсәткечләре нигезендә җаваплы үтәүче карары белән расланган тәртиптә ел саен үткәрелә.

4.2. Тармак стратегияләре мониторингы нәтиҗәләре буенча җаваплы үтәүчеләр хисап елыннан соң килә торган елның 30 апреленә кадәр Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына тармак стратегияләрен тормышка ашыру турында хисаплар җибәрә.

4.3. Тармак стратегияләрен тормышка ашыру турында хисап үз эченә түбәндәгеләрне ала:

а) тармак стратегиясен тормышка ашыру турында аналитик белешмә;

б) конкрет нәтиҗәләр турында, шул исәптән хисап чорында ирешелгән максатчан күрсәткечләр мәгънәләре хакында һәм үтәлгән һәм үтәлмәгән чаралар турында мәгълүматлар (аларны үтәмәү сәбәпләре анализы белән);

в) тармак стратегиясен тормышка ашыру барышына йогынты ясаган факторлар анализы;

г) тармак стратегиясен тормышка ашыруны тәэмин иткән Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыруга файдаланылган бюджет ассигнованиеләре турында мәгълүматлар;

д) тармак стратегиясен тормышка ашыру кысаларында, шул исәптән дәүләт-хосусый партнерлык принципларында җәлеп ителгән бюджеттан тыш финанслау күләмнәре турында мәгълүматлар;

е) тармак стратегиясенә төзәтмәләр кертү ихтыяҗы турында тәкъдимнәр.

4.4. Хисап елы өчен тармак стратегияләрен тормышка ашыру барышы турында хисаплар җаваплы үтәүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырыла.

4.5. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы хисап елыннан соң килә торган елның 30 маена кадәр Тәртипнең 4.2 нче пункты буенча кертелгән хисаплар нигезендә тармак стратегияләрен тормышка ашыру турында җыелма хисапны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыра һәм Татарстан Республикасы Премьер-министрына җибәрә.

4.6. Тармак стратегияләрен тормышка ашыруны мониторинглау нәтиҗәләре буенча җаваплы үтәүчеләр, кирәк булган очракта, тармак стратегияләрен алга таба тормышка ашыру турында, шул исәптән аларга төзәтмәләр кертү ихтыяҗы хакында тәкъдимнәр әзерли.

## 5. Тармак стратегияләренә төзәтмәләр кертү тәртибе

5.1. Тармак стратегияләренә төзәтмәләр кертү буенча тәкъдимнәр формалаштыру максатларында, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан мәнфәгатьле дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары катнашында килештерү киңәшмәләре үткәрү турында карар кабул ителә.

Килештерү киңәшмәләре түбәндәге очракларда үткәрелә:

Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясендә җитди үзгәрешләр булганда;

Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына еллык Юлламасы һәм Татарстан Республикасы Президентының башка йөкләмәләре, шулай ук Татарстан Республикасы Премьер-министры йөкләмәләре кысаларындагы йөкләмәләр нигезендә;

тармак һәм муниципаль стратегияләрне тормышка ашыру нәтиҗәләрен яисә аларның этапларын исәпкә алып;

Татарстан Республикасында һәм Россия Федерациясендә гомуми социаль-икътисадый хәл үзгәргәндә;

хисап елы өчен тармак стратегияләрен тормышка ашыру барышы турындагы хисапларны карап тикшерү йомгаклары буенча.

5.2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары функционалында һәм вәкаләтләр исемелегендә үзгәрешләргә китерә торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарын ябу һәм үзгәртеп оештыру тармак стратегияләренә төзәтмәләр кертү өчен нигез булып тора.

5.3. Төзәтмәләр кертелгән тармак стратегияләре проектлары Тәртипнең 3 бүлегендә күрсәтелгән тәртиптә карап тикшерү һәм килештерү өчен җибәрелә.

___